Республика Татарстан
Совет Чукмарлинского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

20 октябрь 2025 ел

№ 5

Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 18 мартындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Чукмарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» 2020 елның 18 мартындагы 2 номерлы карарына (Советның 12.11.2020 елның №10, 22.02.2023 елның № 2, 24.11.2023 елның №17,07.02.2025 елнын 1 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым ташламаларын бирү:

4.1. шәхси ярдәмче хуҗалык һәм индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә (өлешләренә) карата җир салымы түләүдән азат итү рәвешендә салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә-физик затларга:

4.1.1. Советлар Союзы Геройларына, Россия Федерациясе Геройларына, Дан орденының тулы кавалерларына;

4.1.2. Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәм инвалидларына, шулай ук сугышчан хәрәкәтләр ветераннарына һәм инвалидларына;

4.1.3. инвалидлыкның I Төркеме, инвалидлыкның II төркеме булган инвалидларга;

4.1.4. инвалид балага;

4.1.5. "Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" 15.05.1991 елгы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (18.06.1992 елгы 3061-1 номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә), 26.11.1998 елгы 175 номерлы Федераль закон

нигезендә социаль ярдәм алу хокукына ия физик затларга-"Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында" ФЗ, 1957 елда "Маяк" җитештерү берләшмәсендә булган авария һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар ташлау нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булганнар" һәм "Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында"2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон белән расланган;

4.1.6. аеруча куркыныч янаган бүлекчәләр составында атом-төш һәм термоатом-төш коралын сынауларда, кораллану чараларында һәм хәрби объектларда атом-төш җайланмалары аварияләрен бетерүдә турыдан-туры катнашкан физик затларга;

4.1.7. атом-төш коралын һәм космик техниканы да кертеп, теләсә нинди атом-төш җайланмалары белән бәйле сынаулар, өйрәнүләр һәм башка эшләр нәтиҗәсендә нурланыш авыруы алган яки кичергән яки инвалид булган физик затларга.

4.2. салым түләүчеләрнең түбәндәге категорияләренә җир салымы түләүдән азат итү рәвешендә:

4.2.1. оешмаларга-гражданнарны күмүче җир кишәрлекләренә карата;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернетны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Чукмарлы авыл җирлеге
Советы Рәисе                                        И.Н.Хадиуллин